**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**О присуждении Государственных премий Республики Татарстан имени Габдуллы Тукая в 2019 году**

Рассмотрев предложения Комиссии при Президенте Республики Татарстан по Государственным премиям Республики Татарстан имени Габдуллы Тукая о присуждении в 2019 году в порядке исключения четырех Государственных премий Республики Татарстан имени Габдуллы Тукая, **постановляю**:

1. Присудить Государственные премии Республики Татарстан имени Габдуллы Тукая:

1) Альмееву Надиру Усмановичу – за серии графических работ: цикл «Колокола Хиросимы», иллюстрации к сборникам татарских поэтов, серию пейзажей «Татарстан, Алтай»;

2) Галиуллину Талгату Набиевичу – за роман-эссе «Мөхәммәт Мәһдиев йолдызлыгы» («Созвездие Мухаммата Магдиева»), книгу «Китек көзге» («Отколотое зеркало») и литературно-критическое издание «Мы – потомки страны «Тартария»;

3) группе артистов Татарского государственного Академического театра имени Галиасгара Камала в составе Бикчантаевой (Хамитовой) Люции Миннахметовны, Бариева Радика Зуфаровича, Хайруллина Искандера Ильдаровича за вклад в развитие татарского искусства и создание сценических образов в спектаклях «Гөлҗамал» («Гульджамал»), «Җирән чичән белән Карачәч сылу» («Рыжий насмешник и его черноволосая красавица»), «Кара чикмән» («Черная бурка»), «Өч сеңел» («Три сестры»), «Дон Жуан»;

4) Файзрахманову Айдару Фатхрахмановичу – за вклад в исследование, развитие, популяризацию татарского фольклорного наследия и интеграцию в мировое музыкальное пространство, цикл авторских вечеров «Олы юл», издание двухтомника с нотной обработкой фольклорных произведений «Онытырга мөмкин түгел» и авторских сборников песен и романсов «Яшәү барыбер кызык», «Олы юл», «Борчылма».

2. Кабинету Министров Республики Татарстан обеспечить финансирование расходов, связанных с реализацией настоящего Указа.

3. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
25 апреля 2019 года
№ УП-245

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**2019 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен бирү турында**

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре комиссиясенең 2019 елда чыгарма тәртибендә дүрт Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләген тапшыру турындагы тәкъдимнәрен карап, **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен түбәндәгеләргә бирергә:

1) Әлмиев Надир Усман улына – график эшләр сериясе: «Хиросима чаңнары» циклы, татар шагыйрьләре җыентыкларына иллюстрацияләр, «Татарстан, Алтай» пейзажлары сериясе өчен;

2) Галиуллин Тәлгат Нәби улына – «Мөхәммәт Мәһдиев йолдызлыгы» роман-эссесы, «Китек көзге» китабы һәм «Мы – потомки страны «Тартария» («Без – «Тартария» иле варислары») әдәби-тәнкыйди басмасы өчен;

3) Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының түбәндәге составтагы артистлар төркеменә: Бикчәнтәева (Хәмитова) Люция Миңнәхмәт кызына, Бариев Радик Зөфәр улына, Хәйруллин Искәндәр Илдар улына татар сәнгатен үстерүгә өлеш кертүләре һәм «Гөлҗамал», «Җирән чичән белән Карачәч сылу», «Кара чикмән», «Өч сеңел», «Дон Жуан» спектакльләрендә сәхнә образлары тудырганнары өчен;

4) Фәйзрахманов Айдар Фәтхерахман улына – татар фольклор мирасын өйрәнү, үстерү, популярлаштыру һәм аны дөнья музыкасы мәйданына чыгару эшенә өлеш кертүе, үз авторлыгындагы «Олы юл» кичәләр циклы, нотага салып эшкәртелгән фольклор әсәрләреннән төзелгән ике томлык «Онытырга мөмкин түгел» басмасы һәм үзе иҗат иткән җырлар һәм романслардан төзелгән «Яшәү барыбер кызык», «Олы юл», «Борчылма» җыентыклары өчен.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2019 ел, 25 апрель
№ ПУ-245